РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

№ 2 — 2020 елның 3 феврале

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте буенча Нигезләмәләрне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 5 статьясы, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте буенча Нигезләмәләрне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче кушымтаның 40 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40 Шәхси счетлар

Бюджет керемнәре администраторларының операцияләрен исәпкә алу Федераль казначылыкта ачыла торган шәхси счетларда РФ Бюджет кодексының 220.1 статьясы нигезендә башкарыла.

Җирле бюджетны үтәү буенча операцияләрне исәпкә алу, РФ Бюджет кодексы белән билгеләнгән очраклардан тыш, Федераль казначылыкта бюджет һәм финанслар буенча департаментка ачыла торган шәхси счетларда, бюджет һәм финанслар буенча департаментта ачыла торган шәхси счетларда башкарыла.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

Э.Р.Долотказина